КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 21 март г.Казань № 196

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлекләренә ия булу, алардан файдалану, алар белән эш итү мәсьәләләре буенча мәҗбүри хәбәрләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чаралары исемлеген раслау турында» 2004 ел, 2 апрель, 161 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлекләренә ия булу, алардан файдалану, алар белән эш итү мәсьәләләре буенча мәҗбүри хәбәрләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чаралары исемлеген раслау турында» 2004 ел, 2 апрель, 161 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 14 май, 324 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлекләренә ия булу, алардан файдалану, алар белән эш итү мәсьәләләре буенча мәҗбүри хәбәрләрне бастырып чыгару өчен, шулай ук коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре әгъзаларының гомуми җыелышларын үткәрү турында хәбәрләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чаралары исемлеген раслау турында»

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрнең әйләнеше турында» 2002 ел, 24 июль, ФЗ-101 нче, «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 29 июль, ФЗ-217 нче федераль законнары, «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 29 июль, ФЗ-217 нче Федераль законны кабул итүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 ел, 22 декабрь, ТРЗ-114 нче Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктта «бастырып чыгару өчен» сүзләреннән соң «, шулай ук коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре әгъзаларының гомуми җыелышларын үткәрү турында хәбәрләрне бастырып чыгару өчен» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлекләренә ия булу, алардан файдалану, алар белән эш итү мәсьәләләре буенча мәҗбүри хәбәрләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чаралары исемлегендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлекләренә ия булу, алардан файдалану, алар белән эш итү мәсьәләләре буенча мәҗбүри хәбәрләрне бастырып чыгару өчен, шулай ук коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре әгъзаларының гомуми җыелышларын үткәрү турында хәбәрләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чаралары исемлеге»;

таблицаның «Җир кишәрлегенең урнашу урыны» дигән баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир кишәрлегенең/коммерциягә карамаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтенең урнашу урыны»;

түбәндәге юлны:

| | |
|---|---|
| «Новый Зай» мәгълүмат агентлыгы, «Зәй офыклары» | Зәй районы» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Новый Зай», «Зәй офыклары (Огни Заинска)» | Зәй районы»; |

түбәндәге юлны:

| | |
|---|---|
| «Заветы Ильича», «Заман сулышы» | Лениногорск районы» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Лениногорские вести», «Заман сулышы (Дыхание времени)» | Лениногорск районы»; |

түбәндәге юлны:

| | |
|---|---|
| «Ленинская правда», «Нижнекамское время», «Туган як» | Түбән Кама районы» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Нижнекамское время», «Туган як», «Нижнекамская правда» | Түбән Кама районы»; |

түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | |
|---|---|
| «Казанские ведомости», «Шәһри Казан» | Казан шәһәре». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин